Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 13**

Биектау ав 2016 елның 14 июле

Авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү
буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә;, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне285 карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авылы, Х.Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Янгасала авылы, Калинина урамы, 102 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Мухаметзянов